РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

23 сентябрь 2022 ел № 1-57

Буа муниципаль районы Норлат авыл жирлеге Советының төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 22 ноябрендәге 2-21 номерлы карары (2022 елның 28 февралендәге 1-25 номерлы карар ред), Норлат авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Норлат авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советына төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл жирлеге Советы вәкаләтләрен тапшырырга, аның предметы Норлат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт.

2. Буа муниципаль районы Советына Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлеге советы белән, төзекләндерү өлкәсендә, Норлат авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә тиешле җирлекләр бюджетларына Буа муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән бюджетара трансфертлар хисабына килешү төзүне тәкъдим итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә тәкъдим итәргә:

- Буа муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетына бюджетара трансфертлар бүлү методикалары һәм (яисә) бирү тәртибе нигезендә бюджетара трансфертларның күләмен билгеләргә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2022 елга һәм 2023 елның план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны әлеге вәкаләтләрне кабул итү турында карар чыгару өчен Буа муниципаль районы Советына җибәрергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Норлат авыл
җирлеге башлыгы М.Х. Закиров